ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 март 2019ел № 1142

Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4349 нчы карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Җир кодексының 39.16 маддәсе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4349 нчы карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 22 июнендәге 3190 нчы, 2018 елның 12 ноябрендәге 6625 нче карарлары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын җир участогында урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.9 пунктта:

- 3 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә бирелгән җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килү (шундый гариза белән әлеге

ширкәт әгъзасы (мондый җир участогы бакчачылык яки яшелчәчелек өчен исәпләнгән очракта) яисә гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе чикләрендә урнашкан җир участоклары милекчеләре (җир участогы гомуми билгеләнештәге җир участогы булып исәпләнгән очракта) мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- түбәндәге эчтәлектәге 3.1 пунктча белән тулыландырырга:

«3.1) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы шәхси торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен коммерцияле булмаган оешмага бирелү (әгәр җир участогы әлеге оешманың гомуми файдалануындагы җир участогы булып торса, гариза белән әлеге оешма әгъзасы яисә әлеге оешма мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);»;

- 13 пунктчада «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 16 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«16) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтенә җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы РФ Җир кодексының 39.10 маддәсенең 6 пунктында билгеләнгән чик күләменнән артып китү;»;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып идарәсенә әлеге карар имзаланган көннән башлап җиде көн срокта аны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев